ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

**«14» май 2025 ел** **№ 465**

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 184 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 18 апрелендәге “Татарстан Республикасының өстәмә спорт әзерлеге белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының Дәүләт спорт әзерлеге үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында” 245 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 16 мартындагы “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында” 184 номерлы карарына (Арча муниципаль районы Башкарма комитеты 2022 елның 22 декабрендәге 1126 номерлы, 2024 елның 8 маендагы 316 номерлы, 2024 елның 10 июлендәге 486 номерлы, 2025 елның 4 февралендәге 84 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында күрсәтелгән карар белән расланган Нигезләмәдә:

II бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «II. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

2.1. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгариф хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладры күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура буенча инструктор | 24 900 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | 25 000 |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | 25 140 |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләренең һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә мөдире (башлыгы): кабинет, лаборатория, бүлек, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-җитештерү) остаханәсе һәм гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы башка структур бүлекчәләр | 25 300 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү мәгариф программасын гамәлгә ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 25 350 |

2.2. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Айлык база окладры күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |

| “Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
|---|---|
| Аккомпаниатор | 24 950 |
| “Әйдәп баручы звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары” һөнәри квалификация төркеме | |
| Тавыш операторы | 25 450 |
| Рәссам-бизәүче | |

2.3. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларындагы медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладь күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы»һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы | 25 240 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы <*> | 26 940 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәләренә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 29 170 |

-------------------------------
<*> Вазыйфа буйсынудагы оешмада өч һәм аннан да күбрәк шәфкать туташы булганда билгеләнә.

2.4. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның физик культура хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база окладь күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча кизү торучы | 23 320 |
| | I төркем инвалид спортчыны озата йөрүче | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Спортчы | 23 320 |
| | Алып баручы спортчы | |

| | | |
|---|---|---|
| Икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының<br>һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча инструктор | 24 185 |
| | Спорт буенча Инструктор | |
| | Спортчы-инструктор | |
| | Тренер-ат җайдагы | |
| | Спорт техникасын эксплуатацияләү һәм ремонтлау техникы | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Тренировка процессы администраторы | 24 190 |
| | Адаптив физик культура буенча инструктор-методист | |
| | Адаптив физик культура буенча Тренер-укытучы | |
| | Хореограф | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист | 24 200 |
| | Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы | |
| Өченче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының<br>һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Аналитик (спорт төрләре яисә төркеме буенча) | 24 260 |

2.5. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Айлык база оклады күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| «Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары»<br>һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | 24 900 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау агрономы (урта квалификацияле) | |
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» | | |

| һөнәри квалификация төркеме | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | 24 950 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле агроном | 25 000 |
| | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | 25 060 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәп баручы агроном | 25 150 |
| | Әйдәп баручы зоотехник | |
| | Әйдәп баручы ветеринария табибы | |
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 26 400»; |

28 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28 таблица

Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләренең башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен база окладлары һәм кызыксындыру характерындагы түләүләр күләмнәре

| Җитәкченең хезмәт өчен түләү төркеме | Күләм күрсәткеченең әһәмияте (муниципаль бирем нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә укучылар саны), кеше <*> | База оклады, сум | Башкарылган эшләрнең сыйфаты өчен кызыксындыру характерындагы түләүләр, сумнар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | 0 - 200 | 33 000 | 4 400 |
| 2 | 201 - 400 | 35 200 | 5 500 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3 | 401 - 700 | 39 600 | 5 500 |
| 4 | 701 - 1 200 | 40 700 | 6 600 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 44 000 | 7 700 |
| 6 | 1 801 и выше | 46 200 | 8 800 |
| -------------------------------- <*> Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешманың (спорт-адаптив мәктәп) укучылар контингенты 3 коэффициент белән исәпкә алына.»; | | | |

күрсәтелгән карар белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларның гомуми тармак эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә, җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларына түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең II бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«II. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларның гомуми тармак эшчеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын, җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларын билгеләү

2.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмаларның эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга база оклады күләме, сум |
|---|---|
| “Беренче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| “Икенче дәрәҗәдәге эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре” һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 550 |

2.2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләре гомумтармак вазыйфаларының һөнәри

квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Айга база окладлы күләме, сум |
|---|---|
| “Беренче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары” квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 320 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 520 |
| "Икенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 23 660 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 23 840 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 24 020 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 24 240 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 24 430 |
| "Өченче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 24 620 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 24 820 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 25 050 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 25 250 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 25 450 |
| "Дүртенче дәрәҗәдәге хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары" һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 400 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 600 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 800 |

2.3. Хезмәткәр вазыйфасының һәм һөнәренең эшче, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәренең, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларының квалификация дәрәҗәләренә туры килүе федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

2.4. Бергәләп эшләүче, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү эшләнгән вакытка пропорциональ

рәвештә йә башкарылган эш күләменә бәйле рәвештә башкарыла. Төп вазыйфа буенча, шулай ук бергәләп эшләү тәртибендә биләгән вазыйфа буенча хезмәт хакы күләмнәрен билгеләү һәр вазыйфа буенча аерым башкарыла".

2. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Э. Ш. Вафинага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А. Г. Хисаметдинов